СОВЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода,
422591

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский бистәсе авылы,
422591

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ КАРАР

17.09.2019 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48. №78-339

с. Введенская Слобода

Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә
үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы 1 пункты нигезендә, Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 20.09.2009 ел, № 59-267 карары, Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 20.09.2009 ел, № 13 карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге
карар чыгарды:

1. 2019 елның 17 ноябренә Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегендә яшәүче гражданнарга 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә риза буласызмы?:

- Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә вак таш түшәү.

ӘЙЕ ЮК»

3. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль

районының рәсми сайтында, Введенский Бистәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге
Башлыгы Д.В. Морозов